**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

**КАРАР**
IV чакырылыш _3_ утырыш

2020 елның 04 декабре № _18_ Урыссу ш.т.п.

2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар планлы чорына Ютазы муниципаль районы бюджеты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

**1 статья**

1. 2021 елга Ютазы муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Ютазы муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 575 334,21 мең сум дәрәҗәсендә;

2) Ютазы муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 575 334,21 мең сум дәрәҗәсендә;

3) Ютазы муниципаль районы бюджеты кытлыгын 0 мең сум күләмендә.

2. 2022 елга һәм 2023 елга Ютазы муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Ютазы муниципаль районы бюджеты керемнәренең 2022 елга фаразлана торган гомуми күләмен 578 051,16 мең сум һәм 2023 елга - 582 745,01 мең сум дәрәҗәсендә;

2) Ютазы муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2022 елга - 578 051,16 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 8 728,5 мең сум, һәм 2023 елга - 582 745,01 мең сум күләмендә, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 17 639,1 мең сум күләмендә;

3) Ютазы муниципаль районы бюджеты кытлыгын 2022 елга 0,0 мең сум һәм 2023 елга 0,0 мең сум күләмендә.

3. Ютазы муниципаль районы бюджеты кытлыгын 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 елларның планлы чорына финанслау чыганакларын әлеге Карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

1. Ютазы муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиге

2022 елның 1 гыйнварына 0 мең сум, шул исәптән Ютазы муниципаль районының муниципаль гарантияләре буенча, Россия Федерациясе валютасында муниципаль эчке бурычының югары чиген нуль билгеләнешендә расларга.

2. Ютазы муниципаль районы муниципаль эчке бурычының югары чиген 2023 елның 1 гыйнварына 0 мең сум, шул исәптән Ютазы муниципаль районы муниципаль районы бурычының югары чиген Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр буенча нуль билгеләнешендә расларга.

3. Ютазы муниципаль районының муниципаль эчке бурычының югары чиге 2024 елның 1 гыйнварына 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән Ютазы муниципаль районының муниципаль гарантияләре буенча, Россия Федерациясе валютасында Ютазы муниципаль районының эчке бурычын ноль билгеләнешендә расларга.

**3 статья**

Ютазы муниципаль районы бюджетында 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар планлы чорына Ютазы муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

2020 ел йомгаклары буенча, салымнарны һәм башка мәҗбүри түләүләрне түләгәннән соң калган Ютазы муниципаль районының муниципаль унитар предприятиеләре табышының 2021 елда Ютазы муниципаль районы бюджетына күчерелүе 2021 елның 1 июленә кадәр әлеге табышның 30 проценты күләмендә башкарыла дип билгеләргә.

**5 статья**

1. Ютазы муниципаль районы бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 3 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2. Ютазы муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген әлеге карарның 4 нче кушымтасы нигезендә расларга.

**6 статья**

1. Ютазы муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына әлеге Карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Ютазы муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен әлеге Карарга 6 нчы кушымта нигезендә 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 елларның план чорына бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Ютазы муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне расларга.

3. Ютазы муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (Ютазы муниципаль районының муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 7 нче кушымта

нигезендә расларга.

4. Гавами йөкләмәләрне үтәүгә Ютазы муниципаль районы бюджетының 2021 елга 32 000,9 мең сум күләмендә, 2022 елга - 32 990,0 мең сум һәм 2023 елга - 34 923,3 мең сум күләмендә юнәлтелгән бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен расларга.

**7 статья**

Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм физик затларга, товар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләр, Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә бирелә.

**8 статья**

1.Төзелгән килешүләр нигезендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен, Ютазы муниципаль районы бюджетына җирлекләр бюджетларыннан күчерелергә тиешле бюджетара трансфертлар күләмен исәпкә алырга:

- җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук шәһәр урманнарын, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә урнашкан махсус сакланылучы табигать территорияләрен куллану, саклау, яңадан җитештерү чараларын тәэмин итүгә, 2022 елда - 3601,6 мең сум, 2022 елда - 3601,6 мең сум, 2023 елда 3601,6 мең сум күләмендә, әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә;
- җирлек чикләрендә халыкны электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итүне, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру буенча чараларны тәэмин итүгә, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә, 2021 елда - 4 688,0 мең сум күләмендә, 2022 елда - 4 911,2 мең сум күләмендә, 2023 елда - 5 142,8 мең сум күләмендә, әлеге Карарга 9 нчы кушымта нигезендә;
- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту чараларын тәэмин итүгә 2021 елда - 238,2 мең сум, 2022 елда - 238,2 мең сум һәм 2023 елда әлеге Карарга 10 нчы кушымта нигезендә 238,2 мең сум күләмендә;
- җирлектә яшәүче һәм торак урыннарга мохтаҗ аз керемле гражданнарны торак урыннар белән тәэмин итүгә, муниципаль торак фондын төзүне һәм карап тотуны оештыруга, торак төзелеше өчен шартлар тудыруга, муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруга, шулай ук җирле үзидарә органнарының торак законнары нигезендә башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга 2021 елда - 4 655,0 мең сум күләмендә, 2022 елда - 4 655,0 мең сум һәм 2023 елда - 4 655,0 мең сум күләмендә, әлеге Карарга 11 нче кушымта нигезендә ;
- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген тәэмин итүгә 2021 елда - 6 788,3 мең сум, 2022 елда - 6 788,3 мең сум, 2023 елда 6 788,3 мең сум, әлеге Карарга 12 нче кушымта нигезендә 6 788,3 мең сум;
- ял итүне оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру чараларын тәэмин итүгә 2021 елда 19 258,7 мең сум, 2022 елда - 20 851,7 мең сум һәм 2023 елда 20 769,4 мең сум күләмендә, әлеге Карарга 13 нче кушымта нигезендә;
- җирлек бюджеты проектын төзү һәм карау, җирлек бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен тикшереп тору өчен 2021 елда - 258,7 мең сум күләмендә, 2022 елда - 258,8 мең сум күләмендә, 2023 елда 258,9 мең сум күләмендә, әлеге Карарга 14 нче кушымта нигезендә.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына әлеге статьяда күрсәтелгән бюджетара трансфертларны җирлек бюджетларында күздә тотарга.

3. 2021 елда һәм 2022 һәм 2023 елларның планлы чорында Ютазы муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган җирлекләр бюджетларыннан бюджетара трансфертлар күчерү ай саен тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

**9 статья**

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә җирлекләр бюджетларына дотацияләр күләмен расларга:

– 2021 елга - 18 065,4 мең сум күләмендә,
– 2022 елга - 19 267,2 мең сум күләмендә,
– 2023 елга - 18 026,7 мең сум күләмендә.

2. Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар план чорына тигезләүгә җирлекләр бюджетларына дотацияләр бүлүне әлеге Карарга №15,16 кушымталар нигезендә расларга.

**10 статья**

1. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен расларга:

– 2021 елга - 1 649,2 мең сум күләмендә,
– 2022 елга - 1 666,7 мең сум күләмендә,
– 2023 елга - 1 734,2 мең сум күләмендә.

2. 2021 елга һәм 2022 һәм 2023 еллар планлы чорына хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыру вәкаләтләрен башкаруга җирлекләр бюджетларына субвенцияләр бүлүне әлеге Карарга 17 нче кушымта нигезендә расларга;

**11 статья**

Ютазы муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан 2021 елда һәм 2022 һәм 2023 еллардагы план чорына әлеге Карарга 18 нче кушымта нигезендә алына торган бюджетара трансфертларны исәпкә алырга.

**12 статья**

1.Ютазы муниципаль районы Юл фондының 2021 елга бюджет ассигнованиеләре күләмен - 9 800,0 мең сум, 2022 елга - 10 400 мең сум, 2023 елга - 10 400,0 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2021 елга, 2022 һәм 2023 елларга Ютазы муниципаль районының гомуми файдаланудагы юлларда юл эшләре программасы чараларын гамәлгә ашыруга юнәлтергә.

**13 статья**

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнары 2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләре, шулай ук Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының муниципаль казна учреждениеләре һәм бюджет өлкәсенең башка оешмалары хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел; ләкин моңа Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль

районының муниципаль казна учреждениеләренә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының бюджет өлкәсенең башка оешмаларына яңа функцияләр яисә вәкаләтләр бирү белән бәйле булганда, мондый карарлар кабул итү очраклары керми.

2. Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2021 елда муниципаль хезмәткәрләрнең һәм бюджет өлкәсендәге башка оешмаларның хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәүне тәкъдим итәргә.

**14 статья**

1. Ютазы муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактларга 2020 елда шушы муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар кайтартуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә 2021 елның 1 гыйнварына Ютазы муниципаль районы бюджетының калган акчалары, тиешле карар кабул ителгән очракта, 2021 елда күрсәтелгән максатларга бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**15 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Ютазы муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

**16 статья**

Әлеге карарны http://yutazy.ru адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә массакүләм мәгълүмат чарасында рәсми рәвештә бастырып чыгару юлы белән (интернет челтәре басмасы сыйфатында теркәлү: 07.12.2011 елгы Федераль салым хезмәтенең ЭЛ №ФС 77-47613 номерлы), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр Порталындагы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

**17 статья**

Әлеге Карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**18 статья**

Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы район Советының бюджет, салымнар, инвестицияләр һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы
Татарстан Республикасы Ютазы районы
Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин